ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 пунктының икенче өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре — 2018 елның 13 апреле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин В.П. Привалов шикаятен алдан өйрәнгән судья Ф.Р. Волкова бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин В.П. Привалов «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 9 статьясындагы 2 пунктының икенче өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган нигезләмә белән шул билгеләнгән: бер үк вакытта

Татарстан Республикасы Законының 4—7 статьялары һәм федераль законнар нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган гражданнарга, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәсә, нигезләрнең берсе буенча гражданнар сайлаган социаль ярдәм чаралары күрсәтелә.

Шикаятьтән, аңа өстәмәдән һәм шуларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин В.П. Привалов, хәрби хезмәт ветераны, сугыш хәрәкәтләре ветераны, хезмәт ветераны һәм инвалид статуслары булу сәбәпле, социаль ярдәм күрсәтү чараларын федераль һәм республика законнары белән каралган берничә нигез буенча алырга хокуклы. Мөрәҗәгать итүче «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон белән сугыш хәрәкәтләре ветераннары өчен каралган социаль ярдәм күрсәтү чараларын ала. Шуңа бәйле рәвештә социаль яклау органнары Татарстан Республикасы Законы белән «хезмәт ветераны» категориясе буенча каралган аерым социаль ярдәм чараларын күрсәтүдән аңа баш тарталар.

Гражданин В.П. Привалов Казан шәһәре Киров районы социаль яклау бүлегенә хезмәт ветераны буларак ташламалар бирелмәү сәбәпле салынган зыянны түләттерү һәм әхлакый зыянны компенсацияләү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткән. Казан шәһәре Киров район судының Татарстан Республикасы Югары судының граждан эшләре буенча суд коллегиясенең апелляция билгеләмәсе белән үзгәрешсез калдырылган карары белән гражданин В.П. Приваловка дәгъва таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартылган.

Мөрәҗәгать итүче законнар аңа социаль ярдәм күрсәтү чараларын нигезләрнең берсе буенча сайлау хокукын бирәләр һәм аның социаль ярдәм күрсәтүнең аерым формаларын төрле нигезләр белән каралган башка формалар белән тулыландыру мөмкинлеге бар дип саный. Гражданин В.П. Привалов фикеренчә, сугыш хәрәкәтләре ветераннарына һәм хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү чаралары форма буенча аерыла, димәк, ул хезмәт ветераны буларак Татарстан Республикасы Законының

5 статьясындагы 1 пункты белән каралган кайбер социаль ярдәм күрсәтү чараларын алуга хокуклы: түләүсез теш протезлау, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия, чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонент линиясе өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия.

«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон, гражданин В.П. Привалов күрсәткәнчә, 13 статьясының 3 пунктында турыдан-туры шуны билгели: ветеранның берничә нигез буенча бер үк формадагы социаль ярдәм алырга хокукы булганда, социаль ярдәм, законнарда каралган очраклардан тыш, ветеранның сайлавы буенча бер нигездә күрсәтелә. Республика законының дәгъвалана торган нормасы исә, мөрәҗәгать итүче санаганча, граждан сайлавы буенча нигезләрнең берсе буенча фактта теләсә кайсы социаль ярдәм күрсәтү чараларын аларның формасы аерылуга бәйсез рәвештә алу принцибын беркетеп, федераль закон белән билгеләнгән нигезләмәне тарайта. Шуның белән аның формасы буенча төрле булган социаль ярдәм күрсәтү чараларын сайлауга һәм алуга хокукы чикләнә.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин В.П. Привалов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 пунктының икенче өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясендә ветераннарны социаль яклау гарантияләрен билгели торган махсус закон булып «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба шулай ук — «Ветераннар турында» Федераль закон) тора, аның 1 статьясында сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, хәрби хезмәт ветераннарын, хезмәт ветераннарын кертеп, ветераннар категорияләре билгеләнгән. Социаль ярдәм чаралары

күрсәтелү нигезенә, ягъни ветераннарның теге яки бу категориясендә булуга карап, әлеге ярдәм чараларының исемлеге аерыла.

2005 елның 1 гыйнварыннан «Ветераннар турында» Федераль законның (2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) 22 статьясы нигезендә хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү чаралары Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә. Шуның белән бергә әлеге Федераль законның 13 статьясындагы 3 пунктында шундый кагыйдә билгеләнгән: ветеранның берничә нигез буенча бер үк формадагы социаль ярдәм алырга хокукы булганда, социаль ярдәм, законнарда каралган очраклардан тыш, ветеранның сайлавы буенча бер нигездә күрсәтелә.

Россия Федерациясе Конституция Суды үз карарларында берничә тапкыр шуны күрсәтте: законнарда каралган берничә нигез буенча социаль ярдәмгә берьюлы хокуклы булган затларга социаль ярдәм алучының сайлавы буенча нигезләрнең берсе буенча күрсәтелә торган (законнарда каралган очраклардан тыш), социаль ярдәм күрсәтү чараларыннан файдалануның иң уңай нигезен сайлап алу хокукын беркетә торган шундый хокукый җайга салу гражданнарның хокукларын чикли торган буларак бәяләнә алмый (2011 елның 22 мартындагы 443-О-О номерлы; 2011 елның 21 декабрендәге 1693-О-О номерлы; 2015 елның 29 сентябрендәге 1931-О номерлы; 2016 елның 26 апрелендәге 899-О номерлы билгеләмәләр). Россия Федерациясе Югары Судының хокук куллану практикасы шулай ук шуңа таяна: «Ветераннар турында» Федераль законда социаль ярдәм күрсәтү чараларын төрле нигезләр буенча кушу механизмы юк, һәм ул гражданнарның төрле категорияләре өчен билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларын бер үк зат тарафыннан алу мөмкинлеген бирми (2013 елның 17 июлендәге 9-АПГ13-7 номерлы билгеләмә).

Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы

Законында гражданнарның аерым категорияләре өчен, шул исәптән хезмәт ветераннары өчен күләме һәм формасы буенча конкрет социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгеләгән. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Законында шундый кагыйдә беркетелгән: бер үк вакытта әлеге Законның 4—7 статьялары һәм федераль законнар нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган гражданнарга, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәсә, нигезләрнең берсе буенча гражданнар сайлаган социаль ярдәм чаралары күрсәтелә (9 статьяның 2 пунктындагы икенче өлеше).

Тиңдәш хокукый җайга салу 2016 елның 25 февралендәге 314-О номерлы Билгеләмәдә Россия Федерациясе Конституция Судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. Анда Россия Федерациясе Конституция Суды шуны күрсәтте: «Олы яшьтәге гражданнарга, инвалидларга, хезмәт ветераннарына, Бөек Ватан сугышы чорында тылда эшләгән затларга, балалы гаиләләргә һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында» Хабаровск крае Законының (2006 елның 20 декабрендәге 86 номерлы Хабаровск крае Законы редакциясендә) 8 статьясындагы 2 өлеше нормасы, аның нигезендә берьюлы әлеге закон һәм башка норматив хокукый актлар буенча социаль ярдәм күрсәтү чараларына, алар билгеләнә торган нигезләргә бәйсез рәвештә, хокукы булган гражданга социаль ярдәм чаралары граждан сайлавы буенча я әлеге закон, я башка норматив хокукый актлар буенча күрсәтелә, асылда, «Ветераннар турында» Федераль законның 13 статьясындагы 3 пункты нигезләмәсен кабатлый.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норма, исемлеге Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чараларыннан файдалануның уңайрак нигезен сайлап алу хокукын беркетеп, федераль законнар нормаларына таянган, тигезлек һәм гаделлек конституциячел принципларын бозмый, гражданнарның, шул исәптән гражданин В.П. Приваловның социаль ярдәм күрсәтү чараларын алуга хокукын чикләми һәм, димәк, норманың Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә

билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Карала торган норматив нигезләмәнең конституциячеллегенә дәгъва белдереп, гражданин В.П. Привалов асылда Татарстан Республикасы Конституция суды алдына гамәлдәге норматив-хокукый җайга салуны камилләштерү кирәклеге турында мәсьәлә куя. Шул ук вакытта куелган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 пунктының икенче өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять билгеләнгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин В.П. Приваловка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 4-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**